| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2024 елның «6» мае № 8

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның план чорына «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2023 елның 18 декабрендәге 44 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның план чорына «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2023 елның 18 декабрендәге 46 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

2024 елга бюджетның төп характеристикаларын расларга:

1) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 25 962976,10 сум күләмендә.
2) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 26 982396,10 сум күләмендә.
3) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты дефициты 1019420,00 сум тәшкил итә, аны 2024 елның 01 гыйнварына җирле бюджет акчаларының калдыкларын каплауга юнәлтергә.

2. 2024 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. 2024 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре күләмен әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.
4. 2024 елга «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

5. 2024 елга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетларын классификацияләү чыгымнары төрләренең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.

6. Бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Лениногорск муниципаль районы муниципаль программалары һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре, бүлекләр, 2024 елга бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләре буенча әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.

7. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы авылы, Заречная ур., 25 й., Үзәк ур., 12А йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

8. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

Г.Ә.Мөхәмәтшина